**Татар телендә белем бирү оешмалары өчен әдәбияттан (татар әдәбиятыннан) эш программасына аннотация**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Татар телендә белем бирү оешмалары өчен әдәбияттан (татар әдәбиятыннан) эш программасы |
| Программаны эшләүче | Туган тел (татар) һәм әдәбият(татар) укытучылары |
| Программа кемгә адреслана | 5-9 нчы сыйныф мәктәп укучыларына |
| УМК | -Ф.Ә.Ганиева, Л.Г.Сабирова “ Әдәбият 5 сыйныф” ,Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2014;<br>-Ф.Ә.Ганиева, М.Д.Гарифуллина “Әдәбият 6 сыйныф” ,Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2014;<br>-Д.М.Абдуллина, Л.К.Хисмәтова, Ф.Х.Җәүһәрова” Әдәбият 7 сыйныф” , Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2014, 2 кисәктә;<br>-Ф.Ә.Ганиева, Ч.Р.Рамазанова “ Әдәбият 8 сыйныф”, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2014, 2 кисәктә;<br>-Ә.М.Закирҗанов, Г.М.Фәхретдинова “Әдәбият 9 сыйныф”, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2016, 2 кисәктә |
| Программаның нигезе | - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган «Татар телендә башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа”1-11 нче сыйныф өчен.Төзүчесе: Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Юсупова, Ф.Ф.Хәсәнова. Казан. 2017, “Одобрено решением федерального учебно- методического объединения по общему образованию (протокол от 16 мая 2017г. № 2/17” |
| Программаның максаты | -аерым төр һәм жанрга караган әсәрләрне аңлап укый һәм кабул итә, эчтәлеген кабатлап (аерым очракларда текстны яттан) сөйли, кирәк чакта тексттан өзекләр китерә алуга ирешү;<br>-укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алуына, аның нинди төр һәм жанрга каравын аеруына ирешү; укучының классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белүе;<br>-әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгарып, укыган буенча тезислар һәм план төзү, геройларга характеристика бирү, сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен билгеләү күнекмәсе булдыру;<br>-укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашырга, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларын расларга һәм дәлилләргә, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү<br>-милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә өйрәтү;<br>-әдәби әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт һәм бәя булдыру;<br>-өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүенә ирешү;<br>-автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсен формалаштыру.<br>-әдәби әсәрнең образлы табигате хакында гомуми мәгълүматый күзаллау булдыру, аның эстетик кыйммәтен тою хисе тәрбияләү;<br>-баланың әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта әдәби һәм |

| | |
|---|---|
| | тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белүенә ирешү;<br>-рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә, геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү. |
| Төп бурычлар | -укучының төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне белүенә ирешү һәм анализ барышында кулланырга күнектерү;<br>-укучыда матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗы булдыру;<br>-укучының телдән һәм язма сөйләмен үстерү;<br>-укучыда үз милләтенә, аның әдәбиятына, мәдәниятенә карата хөрмәт, дөньяга гуманлы караш, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, үз милләтенең, шушы төбәктә яшәүче башка халыкларның мәдәни кыйммәтләренә хөрмәт хисләре тәрбияләү |
| Тормышка ашыру вакыты | 5 ел |
| Сәгатьләр саны | Барлыгы: 348 сәгать (5 нче сыйныф – 70с. , 6 нчы сыйныф – 70с., 7 нче сыйныф – 70с., 8 нче сыйныф – 70с., 9 нчы сыйныф – 68с.) |